# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2015 елның 13 гыйнвары 1№

"Иске Камка авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру турында" нигезләмәне раслау хакында.

Россия Федерациясе Конституциясе, 1996 елның 61-ФЗ номерлы «Оборона турында», 1997 елның 31-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында»1997 елның 31-ФЗ номерлы, 1998 елның 53-ФЗ номерлы«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында», 2003 елның 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау турында» 719 номерлы карары, Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты Уставы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. "Иске Камка авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру турында" нигезләмәне расларга.
2. Хәрби исәпкә алуны алып бару өчен җаваплының вазыйфаи инструкциясен расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Камка авыл җирлеге сәркатибы Сагирова Зәйтүнә Әдһәм кызына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.А.Акберов

«РАСЛЫЙМ»
Иске Камка авыл башлыгы
_________ Ф.А.Акберов
2015 елның 13 гыйнвары

# ИСКЕ КАМКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БЕРЕНЧЕЛ ХӘРБИ-ИСӘП ӨСТӘЛЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1.Иске Камка авыл җирлегенең беренчел хәрби-исәп өстәле (алга таба - ПВУС) җирле үзидарә органы администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.
1.2. ПВУС үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, 1996 елның 31 маендагы «Оборона турында» 61-ФЗ номерлы,1997 елның 26 февралендәге «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 31-ФЗ номерлы, 2004.22.08, №122 үзгәрешләр белән, 1998 елның 28 мартындвгы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 53-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге "Хәрби исәпкә алу турында нигезләмә" 719 номерлы, 2005 елның 31 ноябрендәге "Вәкаләтләр бүлешүне камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына "Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запасында булган Россия Федерациясе гражданнарын мобилизацияләү чорына һәм хәрби чорга броньлаштыру буенча Инструкция Һәм запаслары булган федераль башкарма хакимият органнарына һәм дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларында эшләүче Россия Федерациясе гражданнарын броньлау буенча инструкция" кертү турында" 199-ФЗ номерлы карары, Татарстан Республикасы законнары, Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты Уставы, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.
1.3. ПВУС турындагы нигезләмә авыл җирлеге башлыгы тарафыннан раслана.

## II. ТӨП БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Төп бурычлар булып тора:
- гражданнар тарафыннан "Оборона турында", "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында", "Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында" федераль законнарда билгеләнгән хәрби бурычны үтәүне тәэмин итү.
- хәрби исәптә торучы гражданнар турында хәрби исәпкә алу белешмәләрен документаль рәсмиләштерү;
- ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле файдалану өчен хәрби мобилизация ресурсларының микъдари составын һәм сыйфатын анализлау;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрен, башка гаскәрләрне, хәрби формированиеләрне һәм органнарны сугыш вакытына тыныч вакытта мобилизацияләү һәм аларның хәрби вакытта тулануын таләп итеп торган

дәрәҗәдә тәэмин итү чараларын тәэмин итү өчен запаста торучы хәрби өйрәтелгән гражданнар санын әзерләү буенча планлы эш башкару.

## III. ФУНКЦИЯЛӘР

3.1. Җирле үзидарә органы администрациясендә эшләүчеләр арасыннан запаста торучы гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу, хәрби исәпкә алу һәм броньлау буенча көндәлек эшчәнлектә администрациягә йөкләнгән функцияләрнең үтәлешен тәэмин итәргә;
3.2.Запаста яшәүче һәм җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориядә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга;
3.3.Җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген хәрби исәпкә алырга тиешле территориядә даими яки вакытлыча яшәүче гражданнарның Эчке эшләр органнары белән берлектә ачыкларга;
3.4.Авыл җирлеге территориясендә урнашкан оешмаларның исәбен алып бару һәм аларда хәрби исәпкә алуны тикшереп тору;
3.5.Елга ким дигәндә бер тапкыр ТР ВК Әлки районы бүлегенең хәрби исәп документлары, оешмалар, шулай ук теркәлү карточкалары яки йорт китаплары белән беренчел хәрби исәпкә алу документларын тикшерергә;
3.6.Татарстан Республикасы ВК бүлегенең Әлки районы буенча бүлеге начальнигы күрсәтмәсе буенча бүлеккә чакырулар турында гражданнарга хәбәр итәргә;
3.7. Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләрне үз вакытында кертергә һәм 2 атна эчендә бүлеккә кертелгән үзгәрешләр турында хәбәр итәргә;
3.8.Ел саен бүлеккә 15 һәм 16 яшькә кадәрге яшүсмерләр исемлеген 1 ноябрьгә кадәр, ә 1 октябрьгә кадәр - киләсе елда хәрби исәпкә куелырга тиешле яшүсмерләр исемлеген тапшырырга;
3.9. Оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга аларның хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерләү һәм мобилизацияләү буенча Россия Федерациясе законнары һәм хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмә белән билгеләнгән бурычларын аңлату һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту.

## IV. ХОКУКЛАРЫ

4.1. ПВУС планлы һәм максатчан эше өчен хокуклы:
- федераль дәүләт хакимияте органнарыннан, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә учреждениеләрдән һәм оешмалардан кирәкле материаллар һәм мәгълүмат сорату һәм алу буенча тәкъдимнәр кертергә;
- җирле үзидарә органы администрациясенең структур бүлекчәләреннән аналитик материаллар, чараларның җыелма планнары буенча тәкъдимнәр һәм аларны үтәү турында мәгълүмат, шулай ук ПВУСка йөкләнгән бурычларны нәтиҗәле үтәү өчен кирәкле башка материаллар соратырга һәм алырга;

- ПВУС компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмати база булдырырга;
- җирле үзидарә органы җитәкчесе каравына шартнамә нигезендә белгечләрне аерым эшләр башкару өчен җәлеп итү турындагы мәсьәләләрне чыгарырга;
- билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлек итүне оештырырга һәм федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук ПВУС компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча оешмалар белән хезмәт язышуын тәэмин итәргә;
- ПВУС компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча эчке киңәшмәләр үткәрергә.

## V. ҖИТӘКЧЕЛЕК

5.1. ПВУС җитәкли - хәрби исәпкә алу өчен җаваплы -
**Иске Камка авыл җирлеге сәркатибы Сагирова Зәйтүнә Әдһәм кызы**
5.2. Хәрби исәпкә алу өчен җаваплы кеше Иске Камка авыл җирлегенең турыдан-туры буйсынуында;
5.3. Хәрби исәпкә алу өчен җаваплы кеше нигезле сәбәпләр аркасында (отпуск, вакытлыча хезмәткә яраксызлык, командировка) эш урынында булмаган очракта, аны алмаштыра.